РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«1» марта 2023 ел г. Альметьевск № 482

2023 елга Әлмәт муниципаль районы буенча торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чикле индексы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, «Торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен, шулай ук мондый түләүнең күләмен үзгәртүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгына таянып

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәрге чорда торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре ечен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен 10 процент күләмендә үзгәртүне билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

Зак. № 305-2000